Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№13 (64)

18 апрель 2013 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

17 апрель көнне ректор **ИЛШАТ ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ** булды. Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе Андрей Хашов контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм КФУда якын арада булачак чаралар турында мәгълүмат бирде. Аңа җавап рәвешендә, Илшат Гафуров Универсиада авылында автомәктәп булдырырга кирәк дигән тәкъдим белән чыкты: «Безнең студентларыбыз тормышка тулысынча яраклашкан булырга тиеш. Университетта укыган вакытта, йөртү таныклыгы да алсалар начар түгел бит!» Алга таба А.М.Бутлеров ис. Химия институты директоры Владимир Галкин КФУның Үсеш программасы күрсәткечләренә туры китереп 2012/2013 уку елында үзе җитәкли торган институтның эшчәнлеге белән таныштырды. Ул институтның структурасы, кадрлар составы, финанслануы, халыкара хезмәттәшлекләре турында мәгълүмат бирде. Илшат Гафуров институтның күрсәткечләрен арттыру һәм абитуриентларны күбрәк җәлеп итү өчен, Фундаменталь медицина һәм биология институты белән уртак техник тикшерүчеләр, технология булдыручылар әзерли торган программа кирәклеге турында әйтте. Икътисад һәм финанс институты директорының белем бирү буенча урынбасары Илдар Хәйруллин шул ук институтның оешмалар финанслары кафедрасы исемен корпоратив финанслар кафедрасына алыштырырга дигән тәкъдим белән чыкты. Ректор: «Кафедра исеме турында яңадан киңәшләшергә, банк эшләре буенча яңа программа төзергә һәм аннан соң бу темага яңадан кайтырга кирәк», – диде. Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин КФУның РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы оештырган конкурста (университетның конкурентлылыгын арттыру өчен дәүләт ярдәме) катнашу өчен эшләнгән эшләр турында сөйләде. Аның сүзләре буенча, барлык институтлар да кирәкле мәгълүматны биреп бетермәгәннәр. Проректор бу эшне сузмаска кирәклекне әйтте.

• • • •

15 апрель көнне КФУның Яр Чаллы институтында укытучылар һәм студентлар өчен, элекке сәясәт буенча Россия Президенты идарәсе җитәкчесе **ОЛЕГ МОРОЗОВ** белән **ОЧРАШУ ОЕШТЫРЫЛДЫ.** Югары уку йорты өчен традицион саналган әлеге чарада Морозов стипендиясен дә тапшырдылар. Аңа автоматизация һәм прогрессив технологияләр факультетының 5 курс студенты Алинә Шакирова лаек булды.

• • • •

Шул ук көнне КФУ да British Petroleum компаниясенең стипендиаль программасы җиңүчеләренә **ДИПЛОМ** тапшыру һәм фәнни коллективларга **ГРАНТ БИРҮ ТУРЫНДА ТАНЫКЛЫК ТАПШЫРУ ТАНТАНАСЫ** булды. Әлеге стипендия программасының төп максаты – университетыбызның талантлы һәм перспектив студентларын өстәмә стипендияләр белән бүләкләү.

• • • •

13 апрельдә ректор **И.ГАФУРОВ** һәм «Ак Барс» БАНК ААҖ Идарәсе Рәисе **Р.МИННЕГАЛИЕВ** 1 июньдә ачылачак **ПЛАНЕТАРИЙНЫҢ ТӨЗЕЛЕШ ЭШЛӘРЕ БЕЛӘН ТАНЫШТЫЛАР.** Физика институтының әлеге планетарие В.П.Энгельсисемендәгеастрономикобсерватория территориясендә урнашкан. Ул Роскосмом һәм Сколково космик программалары кысаларында РФнең космик системаларының приоритетлы үсеш юнәлеше һәм ТРның космик технологияләренә туры китереп эшләнелә. Ул Идел буе төбәгендә космик тикшеренүләр һәм технологияләрнең төп үсеш объектларының берсе булыр дип көтелә.

• • • •

16 апрельдә КФУның Алабуга институтында **«ЧЫН ТАТАР ЕГЕТЕ-2013»** бәйгесе узды. Анда 6 студент көч сынашты. III дәрәҗәдәге диплом белән Вилнур Сөләйманов бүләкләнде. II урынга Илфат Абдуллин лаек дип табылды. Көндәшләрен артта калдырып, беренче урынга **ИЛНАЗ ШӘЙМӨХӘМӘТОВ** чыкты.

**Ахыры 2нче биттә.**



ТР Хөкүмәте Порталы

# Килешүләр саны арта!

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

15 апрель көнне Прагада КФУ һәм Чехия техник университеты арасында үзара килешү турындагы Меморандумга КФУ ректоры Илшат Гафуров һәм ЧТУ ректоры Йиржи Била кул куйды.

Ректор И.Гафуровның Татарстанның башка эшлекле кешеләре белән ТР Президенты Р.Миңнеханов җитәкчелегендәге делегация составында Чехиягә визиты дәвам итә. Бу чара шушы көнне Чехия башкаласында ачылган Чехия-Татарстан бизнес-форумы кысаларында узды. Чехиядәге татар җәмгыяте – Европада оешкан иң яшь оешмаларның берсе. Бүгенге көндә Чехиядә 300дән артык татар яши. Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез бик актив эшчәнлек алып бара. Биредә 2002 елдан бирле зурлап Сабантуй уздырыла, татар телен өйрәнү өчен бушлай курслар эшли. Визит барышында да Чехия татарлары бик теләп Татарстан кунаклары белән аралашты. Чехиядәге кан-кардәшләребезгә «ТНВ-Планета» проекты, «Ана Теле» on-line программасы турында мәгълүмат бирелде.

Прагадагы Чехия техник университетына 1707 елда Австрия императоры Иосиф I нигез сала. Ул – Үзәк Европаның борынгы техник уку йорты. Анда барлыгы 23 000гә якын студент укый. Укыту чех һәм инглиз телләрендә алып барыла.

Казан федераль университеты актив рәвештә Чехия техник университеты белән хезмәттәшлек итә. Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты ЧТУның математика кафедрасы хезмәткәрләре белән функциональ анализ өлкәсе буенча уртак фәнни тикшеренүләр башкара. Меморандумга кул куелу биомедицина өлкәсе буенча инженер кадрлар әзерләүне тормышка ашырачак.

Шулай ук кичә, ягъни 17 апрель көнне, КФУ ректоры И.Гафуров һәм Масарика ис. университет ректоры Микулаш Бек (Брно, Чехия) арасында үзара килешүгә кул куйды. КФУ ректоры һәм Брно шәһәренең Ветеринар-фармацевтик университеты проректоры Мирослава Лопатаржова үзара хезмәттәшлек турында килеште.

*ТР Хөкүмәте Порталы мәгълүматлары файдаланылды*

## • Бездә кунак бар

# «Иң куркыныч вирус – кулланучы!»

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Кичә, ягъни 17 апрель көнне, КФУның ректорат утырышы залында Dr.Web компаниясе вәкилләре белән очрашу узды.



Әлеге оешма Россиянең антивирус продуктлары эшләп чыгара торган компанияләр арасында иң уңышлылардан санала. Dr.Web төрле операция системаларын кулланучы клиентларга вирусларга каршы көрәш юлларын тәкъдим итү белән шөгыльләнә.

Хәзерге көндә КФУ төп 4 юнәлеш буенча үсеш ала. Беренчедән, университет үзендә моңарчы булмаган биомедицина юнәлешен булдырды һәм бүген аны үстерү өстендә эшли. Икенчедән, нефть промышленносте, өченчедән, мәгълүмати технологияләр тармагы буенча да белем бирү каралган. Дүртенче юнәлеш – гуманитар фәннәр. Бу хакта КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры Данис Нургалиев билгеләп үтте. Аның фикеренчә, бүгенге тизлек заманында мәгълүмати технологияләр һәр өлкәдә кулланыла.

■ Фотода: *Dr.Web компаниясе вәкиле Кирилл Леонов.* Диана Поварова фотосы.

**Ахыры 2нче биттә.**

## • Вакыйгалар әзеннән

15 апрельдә Идарә итү һәм территориаль үсеш институтында **«МАРКЕТИНГ ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬ»** исемле **VIII ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ** булды. Чараның төп максаты – маркетинг өлкәсендә тупланган теоретик һәм гамәли материалларны гомумиләштерү һәм халык хуҗалыгының төрле тармаклы предприятиеләрендә маркетинг эшчәнлеген камилләштерү буенча конкрет тәкъдимнәрне барлау. Икенче көнне конференция «Хәзерге заман шартларында маркетинг һәм логистика белән идарә итүнең тактик һәм стратегик проблемалары» исемле секция утырышы белән дәвам итте.

• • • •

Узган атнада **«ЛОМОНОСОВ-2013»** исемле студент, аспирант һәм яшь галимнәрнең **Х ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯСЕНӘ НӘТИҖӘЛӘР** ясалды. Әлеге традицион ярыш бөтен Россиянең талантлы яшьләрен бергә җыйды. Андагы эшчәнлек хәзерге фундаменталь һәм гамәли фәннәрнең төп юнәлешләрен чагылдырган 32 секциядә алып барылды. Конференциядә КФУдан 38 студент, 7 аспирант, 8 яшь галим, шулай ук Яр Чаллы институтыннан да студентлар катнашты.

• • • •

17-18 апрель көннәрендә Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәдә **«ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫНЫҢ ФӘННИ ҺӘМ УКЫТУ ПРОЦЕССЛАРЫ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮДӘ ЭЛЕКТРОН РЕСУРСЛАР»** исемле региональ фәнни-гамәли **КОНФЕРЕНЦИЯ** булды. Чарада катнашырга дип, Башкортостан республикасы һәм Түбән Новгород шәһәреннән дә килгәннәр иде.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

• Мәнбәр

# Йөрәктә бөреләнгән гамәлләр

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

12 апрель көнне IV республика күләмендә уздырылган югары уку йортлары укытучыларын барлау бәйгесе нәтиҗәләре буенча, иң яхшы укытучылар Филология һәм сәнгать институтында укыта икән!



Әлеге бәйгедә катнашу өчен, 36 укытучы гариза биргән һәм аларның 10сы гына финал өлешенә узган. Анда остазларыбыз «Мин һәм минем профессиям» темасына иҗади презентация һәм дәрестән өзек күрсәттеләр. «Гуманитар фәннәр буенча иң яхшы укытучы» номинациясендә I урынга – Кече ФСИның сәнгать бүлеге деканы, сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасы доценты, педагогик фәннәр кандидаты Мәдинә Мәхмүтова, III урынга шулай ук Кече ФСИның татар филологиясе бүлеге деканы, XX-XXI гасыр татар әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты Гөлфия Гайнуллина лаек дип табылды.

Югары профессионализм планкасын тоту җиңел эш түгел, ләкин Гөлфия Расил кызы мондый дәрәҗәгә лаек икәнен инде күптән дәлилләде. Гөлфия Расиловнаның хезмәтендә иң бәхетле вакыты – студентларга дәрес бирү вакыты икән. Студентларны шәхес булырга өйрәтү, татарның бөек шәхесләре әйтеп калдырган хакыйкатьне җиткерү, милләтебезгә хезмәт итәргә әзерләү мөмкинлеге бирелгәнгә ул үзен чиксез бәхетле дип саный.

«Ә.Еникинең повестьларын өйрәткәндә, кешегә табигать тарафыннан бәхетле булу мөмкинлеге бирелгән, көч салынган, ләкин әлеге потенциалны эшкә җигәргә комачалаучы җимергеч көч тә бар, дигән фикерне табабыз. «Рәшә» повестенда олуг әдип курку хисе – кешедәге иң матур тойгыларны җимерә алучы, аны түбән тойгыларга таба боручы көч, ди. Күңелендә курку хисе йөрткәннәр матди һәм рухи бәйсезлеккә ирешә алмый, үзләре туплаган малның колына әверелә, дигән хакыйкатьне җиткерә. Курку хисен иманга килү – тормышка, милләтеңә мәхәббәтне тану гына җиңә ала.

Хезмәтеңне, милләтеңне чын ихластан ярату бервакытта да җавап хис таләп итми, милләтеңнән җавап хис сорап өзгәләнү, сине яратуларын, тануларын көтү – ул, минем балам кайчан миңа игелек эшли башлар икән, дип көтеп утыру кебек мәгънәсезлек. Милләткә карата кылган гамәлләр йөрәктә бөреләнә».

Укытучының мөгаллимлек хезмәтендә икенче зур юнәлеш барлыкка килде. Ул – институтыбызга, бүлегебезгә сәләтле, максатчан татар балаларын туплау. «Минем максат бер генә – гыйлемгә омтылышлы татар балалары Филология һәм сәнгать институтында канат ныгытып, төрле өлкәләрдә милләтебезгә хезмәт итсеннәр иде. Татар кешесенең бәхетле булу юлы – борынгыны олылап, үз буыны алдында лаеклы һәм җаваплы гамәл башкара алу», дип әйтә укытучы, ә күңеленән зурракка өметләнә.

Гөлфия Расиловна кешеләрдә ихласлыкны, горур-тыйнак эшлеклелекне ихтирам итә. «Кешелек горурлыгы – үзеңә салынган көчне юкка исраф итмичә тиешле гамәлләр кылып яши белү ул. Ә.Еникинең Рәшидәсе әйткән хакыйкатьне студентларыма сеңдерергә телим: «Мәхәббәт уртак булырга мөмкин, сынықны уртаклашырга мөмкин, әмма кешелек горурлыгын урталай бүлеп булмый икән. Кешенең үзенә куйган бәясе бар – шуннан бервакытта да төшмәячәк ул!»

Тормышының тәртибе Күкләр тарафыннан билгеләнгән гамәлләрне үз көенә, кабаланмыйча башкаруда дип күрә ул. Рухи әзерлеге җиткән вакытка олуг шәхесләребез турында зуррак аудиториягә сүз ирештерергә дип язмыш юл сызса, татар һәм рус телләрендә хезмәт язарга исәбе бар икән.

«Минем өчен бер канун ачык – кеше тормышының мәгънәсе – рухи камиллеккә омтылу, кылган гамәлләреңне шул омтылыш белән үлчәү, үлем ноктасыннан бәяләү».

Гөлфия Расиловнаның бу җиңүе соңгысы булмас, дип өметләнәбез. Аңа бу эшендә сабырлык һәм рәхмәтле студентлары күп булсын иде дип теләп калабыз!

• Бездә кунак бар

# «Иң куркыныч вирус – кулланучы!»

**Башы 1нче биттә.**

Данис Нургалиев чыгышында: «Киләчәктә университетыбызда IT юнәлеше буенча магистрлар әзерли торган филиал ачылырга мөмкин», – дип белдерде.

Очрашуда Dr.Web компаниясен **Кирилл Леонов** тәкъдир итте. Белгеч фикеренчә, бүген программист – киң таралган һәм бик кирәкле һөнәр. «Әмма күп очракта айтишниклар үзләренең шәһәрләрендә үсәргә ашыкмый гына, үз көйләренә эшләп яталар һәм Мәскәүгә мәгълүмати технологияләр тармагында эшли торган компаниягә килеп эләккәч югалып калалар. Dr.Web хезмәткәрләрен өйрәтү, укытуга бик зур басым ясый. Бездә хәтта элеккеге табиблар, биологлар мәгълүмати технологияләр өлкәсендә зур уңышларга ирешә. Санкт-Петербургта үсеш алган Dr.Web оешмасының бүген Украина, Франция һәм Япония кебек илләрдә вәкиллекләре бар», – дип сөйләде Кирилл Леонов.

Dr.Web компаниясе КФУ студентлары арасында конкурс үткәрергә җыена. Аның төп максаты: квалификацияле яшь белгечләрне ачыклау, аерып чыгару. Конкурс кысаларында катнашучылар өч сәгать эчендә мөстәкыйль рәвештә бары тик белем-акыллары белән генә компьютердагы вирусларга каршы көрәшәчәк. Әмма бер шарт белән: алар бернинди ярдәмчел программалар һәм интернеттан файдалана алмаячак. Яхшы нәтиҗәләргә ирешкән студентлар бүләкләнәчәк. Иң-иңнәр исә Dr.Web оешмасына эшкә чакырылачак. « КФУда булачак сәләтле программистлар белем алуына шигем юк. Әлеге конкурс – студентларга үсү, өйрәнү һәм тәҗрибә туплау өчен зур мөмкинлек», – дип белдерде Dr.Web вәкиле. Бүген вирус программалары эшләп чыгаручыларның төп максаты – кулланучыдан күбрәк акча суыру. Белгеч белемле һәм тәҗрибәле айтишникларның еш кына әнә шундый зыян китерә торган оешмаларда акча эшләве хакында да әйтеп узды. Кайвакытта алар вирус программаларын эшләүләре хакында белмиләр дә. Мондый күңелсез очраклар булмасын өчен, яшь программистларга үсәргә, үз өсләрендә эшләргә кирәк.

Очрашуда Кирилл Леонов катнашучыларга хәзерге көндә үрчи торган вируслар һәм аларга каршы көрәш хакында да тәфсилләп сөйләде: «Иң куркыныч вирус, әлбәттә, монитор артында утыручы, ягъни, кулланучы. Программаны зыян салучылардан саклау өчен, беренче чиратта, компьютерда вирусларга каршы программа урнаштырырга кирәк. Әлеге программа һәрдаим яңартылып торырга тиеш. Шулай гына вируслар кыркынычы хакында онытырга мөмкин булачак».

• Чара





# Нәрсә ул «Электрон Казан»?

**Рәдифә ШАФИКОВА**

16 апрель көнне «Казан» гранд-отеленең конференц-залында V «Электрон Казан – 2013» халыкара фәнни-гамәли конференциясен ачу тантанасы һәм пленар утырышы узды.

Форум 2009 елда, беренче катнашучыларны җыеп танылу ала һәм традицион чара булып формалаша. «Узган елларда үткәрелгән дүрт конференция дә зур уңыш белән тәмамланды һәм тирә-юньдәгеләрдә кызыксыну хисе уятты. Нәкъ менә узган елларның уңышы әлеге форумны үткәрүгә этәргеч булды», – диде форум җитәкчесе ярдәмчесе, Социаль һәм гуманитар белем бирү институты проректоры Кирилл Понамарев.

Чыннан да, конференциядә катнашучылар саны елдан-ел арта. «Электрон Казан – 2013» ул – йөздән артык белем бирү учреждениеләрен тәкъдим иткән Россия һәм чит илләрнең илле шәһәреннән 250 теркәлгән катнашучы дигән сүз.

Әлеге 5 ел дәвамында Казан федераль университеты конференцияне оештыручылар санына керә һәм актив катшнашучысы булып тора. Фәнни форумның ачылу тантанасында КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры Данис Нургалиев та катнашты. Ул КФУның тарихы һәм бүгенге эшчәнлеге буенча кечкенә генә экскурсия оештырды. КФУ форумның пленар утырышында да тәкъдир ителде. «Парадигма открытого образования в рамках реформирования образовательного пространства вуза» доклады белән белем бирү ресурсларын үстерү департаменты директоры Галина Ившина чыгыш ясады. Ул үз чыгышын «Яңа буынга яңа типтагы белем бирү кирәк», – дип башлап җибәрде һәм «ачык мәгариф» терминының мәгънәсен аңлатты, аның үзенчәлекләрен, чит төбәк вузларыннан тупланган тәҗрибәдән файдаланып, мисаллар китерде.

Галина Васильевна Казан Университетының әлеге өлкәдәге эшчәнлеге һәм уңышлары белән уртаклашты. Аның сүзләре буенча, бу ел эчендә КФУда дистанцион белем бирү системасы сайты ачылды. Әлеге сайтта MOODLE платформасына ориентлашкан берничә мәйданчык бар. 600 артык дистанцион курсларда 15 меңгә якын студент эшли һәм 300 якын укытучы үз квалификациясен күтәргән.

Конференция 18 апрельгә кадәр дәвам итәчәк. Анда заманча белем бирүдә челтәр технологияләре, белем бирүнең электрон ресурслары турында фикер алышачаклар.

